


24 нче октябрь көнне 5 нче сыйныф укучылары белән Башкортостанның халык шагыйре Мостай Кәримнең 100 еллык юбилеена багышланган сыйныфтан тыш чара үткәрелде. Татар теле укытучысы Сәләхова Р.С. балаларны шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштырды, Яруллина Г.С. бай презентация күрсәтте. Укучыларга М.Кәримнең үз тавышы белән рус һәм татар телләрендә укыган шигырьләре, җырчы Фидан Гафаров башкаруында шагыйрь сүзләренә язылган “Язмыштан узмышлар” җыры бик ошады. Чара ахырында әдип иҗаты турында фикер алышу булды.